СӨЯ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 8 июленнән бирле чыга. | №69 (7242) | 13 июнь, 1991 ел. ПӘНҖЕШӘМБЕ | Бәясе 4 тиен.

## Байрак „Үрнәк"тә кала

КПСС райкомы бюросы, халык депутатларының район Советы башкарма комитеты, АПК работниклары профсоюзы райкомы президиумы һәм ВЛКСМ район комитеты бюросы май аенда колхоз-совхозлар арасында терлекчелек продукциясе җитештерү буенча социалистик ярыш нәтиҗәләрен карадылар.

Май аенда бер сыерга уртача 431 килограмм сөт җитештергән «Үрнәк» колхозы янә җиңүче дип табылды.

Сөт савуда узган ел белән чагыштырганда иң зур —44 әр килограмм үсешкә ирешкән «Таң» колхозы бу төр ярыш буенча беренче булды.

Әлеге хуҗалыкларга КПСС райкомы, халык депутатларының район Советы башкарма комитеты, АПК работниклары профсоюзы райкомы һәм ВЛКСМ райкомының Кызыл байракларын тапшырдылар.

Карарда май аенда сөт җитештерү һәм аны арттыру буенча «Знамя Октября», «Большевик», «Россия» колхозларының әйбәт эшләүләре билгеләнде.

Синдряков исемендәге, Хафизов исемендәге колхозлар, «Сөлчә» совхозында узган елның шул чоры белән чагыштырганда сөт җитештерүнең 67—54 килограммга кимүе тәнкыйтьләнде.



## Арендачы чөгендер үстерә

«Таң» колхозында аренданың таркалуына юл куймадылар. Райондагы күпчелек хуҗалыклар бу ысул белән эшләүдән бернинди файда да, табыш та юк дип кул селтәгән чагында, алар киресенчә, көннән-көн ныгый баралар. Икенче төрле әйткәндә, «Арендага—яшел урам» дигән әйтем алар өчен үз мәгънәсен җуймады.

Уңышка барың бер булып эшләгәндә генә ирешергә була. Моны Рияз Сәлимович Гайфуллин җитәкчелегендәге звено членнары яхшы аңлыйлар. Шуңа бар тырышлыкларын куеп, фидакарьлек күрсәтеп эшлиләр дә.

Арендачы Раил Шакирҗанович Сөләймановның да инде алты еллык эш стажы бар. Ә арендада ул икенче елын эшли. Шул дәвер эчендә Раил Шакирҗанович үзен сәләтле һәм тырыш механизатор итеп танытты.

Хәзер аның өчен эшнең иң кызу вакыты. Ул 80 гектар мәйдандагы татлы тамыр плантациясендә рәт араларын эшкәртә. Хатын-кызлар исә аның артыннан сирәкләү эшләрен башкаралар.

Рәсемдә сез арендачы Раил Шакирҗанович Сөләймановны иртәнге сәгатьләрдә кырга чыгар алдыннан күрәсез.

## Җитди сигнал

Мин 4 июнь көнне шәһәрнең Лермонтов урамындагы азык-төлек кибетеннән ак май сатып алдым. 1 талонга төп-төгәл 500 грамм май үлчәп бирделәр. Әмма ул майны күрсәгез иде: өстендә җылыга эрегән саргылт катлам өстендә зәңгәрсу-яшькелт күгәргән тимгелләре дә бар. Шул хакта әйткәч тә кибетчеләрнең исе китмәде. Хәләл акчабызны түләп аена 500 грамм май алабыз, шунда да рәнҗетмичә калдырмыйлар. Безнең тимер юлчылар поселогында өлкән яшьтәгеләр бик күп яши. Инде алар май эзләп Кормыш ягына ук йөрергә тиешмени?

Г. ВӘЛИЕВА.

## Үз көчләре белән

«Үрнәк» колхозында 140 гектар чөгендер чәчелде. Ул 37 алынга бүленеп халыкка бирелде. Без читтән килгән ярдәмне көтмичә бу алыннарны үз көчебез белән эшләп чыгарга булдык. Әйтергә кирәк, хатын-кызларның тырышлыгы аркасында сирәкләүне бетереп килəбез.

Ә тракторчыларыбыз Ринат Нямаев һәм Инис Хәйдәрҗанов икенче тапкыр шаровкалауга төштеләр.

## Бүгеннән тырышабыз

Җәмәгать маллары өчен азык әзерләү чоры җитте. Җәйге көннең җитештерүчән хезмәте кышкы чорда турыдан-туры продукция муллыгын тәэмин итәчәк. Шуңа да азык әзерләү кампаниясен оешкан төстә үткәрүгә безнең хуҗалыкта һәр елны зур игътибар бирелә. Менә шушы көннәрдә генә «Татарстан» колхозының 170 гектарлы күпьеллык үлән басуында азык әзерләүгә керештек. Бирелә 6 агрегат эшли. Фоат Вәлиев, Рафик Мингалимов, Рифкать Нуруллин, Марс Беляев, Рифгать Низамов, Әхәт Гыйниятуллин КС-2,1 чапкычлары белән үләннәрне чабуда беренче көннәрдә үк әйбәт темп алып эшли башладылар. Узган ел без күпьеллык үлән массасын нигездә сенажга салган идек. Быел, көннәр әйбәт кенә торса, аны күбрәк печәнгә алырга ниятлибез. Участоклар быел елына күрә әйбәт кенә уңыш вәгъдә итәләр. «Күрәсезме, бу бит минем хезмәт»,—дип Фоат ага урынлы горурлана. Чөнки ул яз көне бу мәйданнарга ашлама сибә, уңыш муллыгы аның хезмәтенә турыдан-туры бәйле. Ә Фоат ага башкарган эш өчен җан тыныч безнең. Хуҗалыкның иң өлкән механизаторы ул. 1953 елдан бирле техника иярли. Әхәт ага Гыйниятуллин, Рафик Мингалимов та тәҗрибәле механизаторлар. Ә калганнары—яшьләр, типсә тимер өзәрлек энергияле чаклары әле. Әнә Рифгать Низамов 3 нче елын эшли. Алар елы егетләре класслары белән диярлек авылда калдылар, бик эшчән, булдыклы егетләр. Рифгать язгы чәчүдә техниканы ягулык-майлау материаллары белән заправкалауда эшләде. Инде хәзер менә азык әзерләүчеләргә кушылды. Алар чапкан массаны Мидхәт Дәүләтшин КПИ-2,4 агрегаты белән тапатып АВМ-га ташып тора. Витаминлы үлән оны әзерләү быел да Әфгать Нотфуллин җаваплылыгында. Ул безнең профсоюз комитеты рәисе, 6 нчы ел инде җәен кул астына тырыш кына укучыларны туплый да маллар өчен бик кирәкле үлән оны әзерләүдә эшли. Хәзер үк алар 12 тонналап үлән оны җитештерделәр инде.

Әнә шулай хуҗалык азык әзерләү кампаниясенә уңышлы гына керешеп китте. Маллар тук кышласын, продукция муллыгын киметмәү өчен аны мөмкин кадәр күп һәм сыйфатлы итеп туплап калуны максат итә колхочылар.

Р. НАСЫЙБУЛЛИН, партоешма секретаре.

## Хезмәт хакы артты

**Район элемтә узелы коллективының хезмәт хакы нинди күләмдә булуга карамастан, эшчеләргә өстәмә рәвештә 100 сум компенсация бирелә. Моңардан тыш хат ташучыларга газеталарны үз вакытында китергән өчен—30, пенсияне—40, ашау өчен—40 һәм 60 сум компенсация түләнә. Бүгенге көндә хат ташучыларның айлык хезмәт хакы 535—540 сум тәшкил итә. Элек 110 сум акчага эшләп йөргән күп стажлы һәм мактаулы эшчеләр бу яңалыктан бик канәгать калдылар. Үз эшенең чын осталары хат ташучы Александра Павловна Филиппова, оператор Сәкинә Салиховна Садыйкова, телефонистка Светлана Ивановна Мөхәмәтҗанова, сортларга аеручы Ирина Александровна Попкова, гомумән, элемтә хезмәткәрләре барысы да зур күңел күтәренкелеге тоеп эшләп йөриләр бүген.**

**И. ЛАТФУЛЛИНА, экономист.**

## Сайлау участогында

—Хәзер халык активлаша төште,—диде 33 нче участок сайлау комиссиясе рәисе Мөбин Минһаҗетдинович Фәхриев.—Эшкә бару алдыннан сайлап китәргә ашыгалар.

33 нче номерлы Норлат-Октябрь сайлау участогында Татарстан Президентын сайлауга халык шулай агыла торды. Сайлау комиссиясе членнары һәр килүчене тоткарламый бюллетеньнәр бирергә ашыктылар.

Р. ЗАҺРЕТДИНОВ.

## Поездлар нигә тукталды?

**Казан—Уфа, Уфа—Казан поездларының туктатылуы районыбыз халкын аяныч хәлгә калдырды. Гаҗәп тә түгел: бу—җөмһүриятебез башкаласына йөрүче бердәнбер поезд иде. Шуңа күрә анда бару һәм кайту шактый мәшәкатьләр белән бәйләнәчәк. Ул ни сәбәпле туктатылды соң? Халыкны Казанга тимер юлдан йөртү өчен нинди булса да чаралар күреләме? Шул сораулар белән без Норлат станциясе начальнигы Л. Н. ГАЗИЗУЛЛИНАга мөрәҗәгать иттек.**

—Горький тимер юлының Казан бүлекчәсе соңгы вакытта хуҗалык исәбенә күчеп эшли башлау сәбәпле Казан—Уфа поездының табыш китермәвен ачыклаган. Ул Татарстан Министрлар Советы рөхсәте белән аны туктатуга ирешә. Бу хакта Ульяновск һәм Норлат станцияләре җитәкчелеге белми дә калды. Нәтиҗәдә алар безне шундый факт алдына куйдылар: халыкны озатырга поезд юк.

Без бу хәлдән соң Куйбышев тимер юлы җитәкчелеге белән очраштык. Алар озакламыйча я шул поездны кире гамәлгә кертү яисә тагылма вагоннар бирәчәкләре турында ышандырдылар. Үзгәреш булуга газета аша хәбәр итәргә тырышырбыз.

## Чирмешән буйлары ямьле

Кизләү халкы Чирмешән буендагы яшел аланга әле өченче елын гына җыела. Кемнәрдер бирегә атлар ярышын карарга киләләр, икенчеләрен көрәш кызыксындыра, өченче берләре нинди дә булса күңелгә хуш килерлек товар сатып алу максаты белән янып йөри. Ничек кенә булмасын, сабантуй сабантуй инде, һәркем үзенчә күңел ачып калырга тели.

Мәйданга җыелган халыкны КПСС райкомы вәкиле буларак килгән сәүдә базасы директоры Ислам Салихович Сафиуллин котлады. Аннан сүзне «Чишмә» колхозы рәисе Х. Х. Шәйхетдинов алды. Ул язгы чәчү барышына йомгак ясады, алдынгыларның исемнәрен атады. Беренче урын Кәлимулла Нәбиуллович Зәйдуллин җитәкчелегендәге агрегатка бирелде. Аннан соң уеннар, ярышлар башланды.

Атлар ярышында Мичурин исемендәге колхоз җайдаклары да катнашты. «Буян» атында беренче булып Станислав Николаев, 2 нче булып «Полянка» аты белән Илшат Мингалимов килделәр.

Көрәш буенча беренче урынны хуҗалык шоферы Фәнил Кәримов алды.

Тимер юл ОРСы, Кизләү ваклап сату предприятиесе дә бу көнне кызу сәүдә иттеләр. Алар халыкка промышленность товарлары, пешкән кондитер әйберләре саттылар. Әнә шулай ямьле Чирмешән буенда бәйрәм гөрләп узды.

З. ХӘММӘТШИНА, баш бухгалтер.

## ● Бер колхоз хәбәрләре



Авыл җирен үз итте Зәйтүнә, аның да иң мәшәкатьле, иң авыр хезмәтен—терлекче һөнәрен сайлады. Менә 18 ел инде ул XXI партсъезд исемендәге колхозда сыерлар сава. Хезмәтен җиренә җиткереп, сөеп башкарганга, исеме һәрчак алдынгылар рәтендә, күрсәткечләре әйбәт була аның. Шуңа коллективта абруе да зур.

Хәзер хуҗалык малларны җәйләүгә алып чыкты, биредә сөт муллыгы өчен киеренке көрәш бара. Зәйтүнә Гомәровна да бу ярышның алгы сафында. Колхоз терлекчеләре көнгә уртача һәр малдан 11,6 килограмм сөт саусалар, Хамматова группасында ул күпкә югары.

Рәсемдә: XXI партсъезд исемендәге колхоз сыер савучысы З. Г. Хамматова.

## Авыл төзекләнә

Яңа Әлмәт авылында яңа балалар бакчасы төзелеп бетү алдында. Бу—моңарчы ике бинада гына урнашкан бакчаның киләчәктә тәрбия мөмкинлекләрен бермә-бер киңәйтәчәк. Хуҗалык быел хуҗалык исәбе белән 4 фатир төзи, 1 нче бригадада ашлык склады да кора.

## Күңелле ял иттек

Сабан туйлары, татар халкының милли бәйрәме шулкадәр якын бәйрәмгә әйләнде, хәтта аны чуваш авылларында да яратып үткәрәләр. Шундый сабан туе Илюткино авылында да үтте. Хәер, бу ике ел элек оешкан «Москва» колхозы чуваш авылы белән бергә татарныкын да (Әхмәт) берләштерә. Яңа хуҗалык булып оешканнан бирле без инде икенче сабан туен үткәрәбез. Сабан туе бәйрәме колхоз оешуга ике ел тулу көненә туры килгән иде, шуңа да ул колхозчылар өчен икеләтә бәйрәм иде.

Бәйрәм бик матур, аяз иртәдә башланып китте. Колхоз рәисе Анатолий Германович Гаврилов хуҗалыкның язгы чәчүне ничек башкарып чыгуы белән таныштырды. Колхоз өчен иң җаваплы эштә яхшы күрсәткечләргә ирешүчеләргә карата мактау сүзләре әйтте һәм бүләкләр тапшырды.

Башка сабан туйларындагы кебек үк биредә дә төрле ярыш уеннары оештырылган иде. Билгеле булганча, һәр ярышның үз җиңүчесе була. Ат чабышында колхоз терлекчесе Васыйл Галимов иң беренче килде. Бу ярышта катнашу максаты белән башка колхоздан да чаптарлар килгән иде. Шулар арасыннан «Таң» колхозы чабышкылары II нче һәм III нче урыннарны алдылар.

Капчык киеп узышканда Хәлил Хәйбуллинның иң оста йөгерүче икәнлеге беленде. Капчык белән сугышучылар арасында Николай Петров иң җитез һәм көчле сугышчы булып танылды. 100 метрга йөгерү ярышларында Андрей Ефремов иң беренче килде. Шунда ук ике бригада арасында футбол, волейбол уеннары да үткәрелде. Икесендә дә беренче бригада (Илюткино авылы) уенчылары җиңүче булдылар.

Татарча көрәш безнең сабан туенда да бәйрәм күрке иде. Байтак кына көрәшчеләр арасыннан Кадыйр Хәйбуллин колхоз батыры булды һәм тәкәне алуга ирешә. Ә кунак-көрәшчеләр арасында Җәмил Хәйруллинга тиңнәр булмады.

Шулай итеп сабан туенда күңелле ял иттек.

**И. ГАФУРОВ.**

## Армый эшләгез, апайлар

Тирә-юньне каплап йөргән болытлар, шөкер, чөгендер кырын урап үттеләр. Хәзер яңгыр туктасын, чөгендерен эшләргә, печәнен җыярга җай бирсен иде. Арыш серкәләнер өчен дә кояш кирәк. Авыл кешеләре шул турыда еш телгә ала башладылар. Чөгендер кырында кыска ялга утырган апайлар да шундыйрак гәп коралар.

—И, авыл кешесенең мәшәкате гел бетми инде,—диештеләр. Менә чөгендерне дә ничә ел эшлибез, эшлибез—тешләп чәй эчәргә конфетка тиенгәнебез юк.

Чыннан да, гомер буе чөгендер кырында эшләгән апайлар алар. Әнә алда Искра Зәйдуллина, Разия Вәлиуллина, Тәзкирә Хәммәтвәлиева, Фатыйма Шәяхмәтова, Әминә Гыйниятуллина, Асия Шәкүровалар эшли. Җәен чөгендер иксәләр, кышын янә колхоз эшенә алар чыга.

Әнә чөгендернең беренче катын эшкәртүләре. Быел, сөбханалла, чөгендер әйбәт кенә күренә. Кайбер хуҗалыклардагы кебек яңадан чәчәсе дә булмады, куелыгы да чамалы гына. Аркылы эшкәртүне кирәксенмәделәр. Ызан башында механикалаштырылган звено җитәкчеләре Гомәр Фәтхетдинов белән Ирек Минапов тракторлары белән рәт араларын икенче кат эшкәртәләр инде. Гомәр өчен бу—күнегелгән эш, 10 ел инде чөгендер игүдә ул. Шуңа беренче ел басуга чыккан Ирек Минаповка киңәшне әледән-әле биргәләп тора. Шунсыз ярамый, чөнки чөгендер җире тулысынча алар җаваплылыгында: алар чәчтеләр, рәт араларын эшкәртәләр, уңышны да алар ук җыячак. Быел алдагы еллардан аермалы буларак, төп бәяләргә өстәмә рәвештә эшкәртелгән һәр гектар өчен берәр сум исәбеннән түләү үткәрү каралган. Ике эшкәртәләрме, өчме—бу көчендә кала. Иң мөһиме—уңыш әйбәт үссен, апайларга эш җиңеләйсен.

Бик җиңелләрдән түгел шул чөгендерче хезмәте. Әлеге дә баягы, гел шул китмәннән узмый эш коралы. Сөлмә Нуруллина, Җәмилә Нотфуллина, Руфия Шәкүрова, Әлфия Хәсәнова да ничә ел инде кояш астында китмәннән, яңгыр астында пычрактан аерылмыйлар. Әлфия апа көлә: 12 яшемнән бирле, ди.

Апайларның күбесе пенсия алды яшендә. Алар буыны дәррәү ялга китсә, кем алыштырыр чөгендерчеләрне? Карап торырга кәефле күренсәләр дә буыннары да ватылган, куллары да сызлый аларның. Ә җор телләләр.

—Җор телле генә түгелләр, якты күңелләләр дә. Әнә безнең Әлфиябез шигырьләр дә яза,—ди авыл Советы рәисе Ф. Нургалиев. —Бәйрәм саен авылдашлары аның шигырьләрен тыңлап куаналар.

Әлфия апа мактаганда кызарып кына китә. И, анысы бит аның болай, күңел кузгалганда гына. Хәзер шулай үз кәефеңне үзең күрсәң генә. Әнә гомер тулы кибет киштәләре гел шып-шыр калдылар. Апайлар бер нәрсәгә куаналар: ярый әле үзебез әзерләгән вареньенигъмәтләр бар. Кычыткан лы—җиләкле, нигъмәтле як бит. Заманында шикәр комы иркен чагында кура җиләге вареньесы белән иләк тә тула, чиләк тә тула иде. Хәзер шул запаслар да кузгалды. Быел карлыган бик матур күренә, кура җиләге дә булырга ошый—тик менә шикәр комын каян аласы? Апайлар бер тавыштан сорыйлар: чөгендернең беренче катын эшкәртүгә үк аванс тәртибендә шикәр комы бирмәсләр микән? Аның иң кирәк чоры—нәкъ шул җәй бит.

Бу мәсьәләне уйламый калмаслар дип ышаныйк. Чөнки чөгендерчеләргә юк-юк та кәеф тудырырлык нәрсәләр эшләнеп тора: әнә, районнан алар өчен махсус азык-төлек наборы кайтарылган. Кибеткә кайткан трикотаж әйберләреннән дә беренче аларга өлеш чыгармакчылар. Эшләсеннәр генә, әйбәт уңыш кына үстерсеннәр—колхоз идарәсе аларның һәр үтенечен канәгатьләндерергә тырышканга ошый.

Апайлар үзләре дә шуны телиләр—эшләрлек көннәр торсын, уңышлы ел килсен. Шуңа да сөйләшү тәмамлануга тизрәк китмәннәренә тотындылар. Армый эшләгез, апайлар!

**С. ХӘЙРУЛЛИНА,**
«Татарстан» колхозы.

## Вакыйгалар—сезнең хөкемгә

Җинаятьләр буенча районда хәл шактый катлаулы. Апрель-май аенда гына да 42 җинаять эшләнгән. Шуның күпчелеге шәхси һәм дәүләт милкен урлаудан гыйбарәт.

14 апрель төнендә урман промышленносте хуҗалыгы ОРСы кибетеннән сигаретлар һәм магнитофон кассеталары урлыйлар.

17 апрельдән 18 енә каршы төндә җәмәгать туклануы предприятиесе складыннан спиртлы эчемлекләр урлана. Тикшерү барышында бу эш буенча кулга алынган ике кешенең моңа кадәр башка урлауларда да өлешләре барлыгы ачыклана.

Апрель ахырында Норлатта, Торнаяста, Андреевкада мотоцикл урлау очраклары булды. Әлеге җинаятьләр буенча тикшерү алып барыла.

x x x

Исереклектән җинаятькә бер генә адым дип юкка гына әйтмиләр шул. Апрель-май айларында эчкән килеш җәмәгать урыннарында йөргән өчен 199 кеше тоткарланды һәм административ җаваплылыкка тартылды. Алар арасында җәмәгать тәртибен һәм законлылыкны бозган өчен икешәр-өчәр тапкыр әләгүчеләр дә бар. Һәм мондыйлар арасында нинди генә яшьтәге, нинди генә хезмәттәге кешеләр юк! Мәсәлән, шуларның берсе—Норлатта яшәүче Ю. Кабанов беркайда да эшләми. ЛТПда дәваланып кайтуына карамастан, эчү гадәтен ташламый, аена өчәр тапкыр милициягә эләгә. 65 яшьлек пенсионерка Х. Гыйниятуллина (Норлатта яши) эчүчеләрне җыеп ятканы өчен җәзага тартылды. Норлатта ветстанциядә эшләүче Н. Еремеева, «Төрнәс» совхозы эшчесе В. Захаров, «Рассвет» совхозыннан Д. Сатдаров, Норлатта яшәүчеләр С. Веренцов һәм И. Шәйдуллин, шундый «атказанган» тәртип бозучылар булып торалар.

x x x

Вак хулиганлык өчен бу чорда 182 кеше административ җаваплылыкка тартылды. Шуларның күбесе—эчкән килеш гаиләсендә яки җәмәгать урынында җәнҗал чыгаручылар. Аеруча актив «җәнҗалчылардан» НУАД эшчесе В.Хисмәтуллин,«Сельхознерго» шоферы Р. Хәбибрахманов, шулай ук Норлаттан В. Шкурин, Р. Медведева, А. Большаков, В. Глухов, М. Петров, Яңа Иглайдан И. Сабитов, Чуваш Мәнҗесеннән В. Илюхинны атап әйтергә мөмкин. Әмма аларның да «зәвыгы» төрлечә. В. Хисмәтуллин исерек килеш урамда бәйләнергә ярәтса, Ф. Хәбибрахманов һәм В. Шкурин шәһәрнең бию мәйданчыгында җыелган яшьләрнең «игътибар үзәгендә» йөрергә, «көн герое» булырга ярәталар. Ә Р. Медведева күршеләре өчен «түләүсез кәмит» оештырырга ярата. 1952 елгы бу хатын-ана кеше үз гомерендә дүрт тапкыр хөкем ителгән. Быелның 9 гыйнвареннан бирле беркайда эшләми. 14 яшьлек улының пенсиясенә кинәнеп эчеп ята. Күршеләренең шикаятьләре нигезендә бүгенге көндә аңа махсус күзәтчелек оештырылды. Ә менә шундый ук җәнҗаллар күпләр өчен фаҗига белән тәмамланган. Мәсәлән Н. Ибниев газиз әтисен кыйнаган, М. Кәлимуллин хатынына пычак белән кадаган, В. Баскаков—әтиәнисен, ә Е. Наумов үзенең элеккеге хатынын кыйнаган. Мондый очраклар буенча шулай ук хөкем эше кузгатылды.

Җәнҗал ягына килгәндә, «осталык» ягыннан районның культура-агарту белән шөгыльләнүче кадрлары арасында да бар икән андый «сәләтлеләр». Каян белдегез дисезме? 16 май көнне милиция нарядлы телефоннан алынган ашыгыч хәбәр буенча Илюткинога китте. И. Фомин дигән берәү исерек хәлдә колхоз рәисенә бәйләнгән икән. Милиция наряды Фомин хуҗалыгына килеп җитүгә аларны хуҗаның кызы Зинаида Ивановна (соңыннан билгеле булганча, авыл культура йорты директоры булып эшли икән) каршылады. Өйләрендә табылган бер фляга әче балны бирмәс өчен ул безнең хезмәткәрләргә нинди генә сүзләр кычкырмады, хәтта өстебезгә әче бал да сипте. Азау ярган хулиганнардан да ишетмәгән сүгенү сүзләре ишеттек без бу көнне яшь кыз авызыннан. Әмма авылның культура үзәге җитәкчесенең тырышлыгы юкка булды, ата кеше җавапчылыктан кача алмады: вак хулиганлыгы өчен 5 тәүлек утырып чыкты, әче бал ясаганы һәм аны өендә саклаганы өчен 300 сум штрафка тартылды.

02 хәбәр итә

x x x

Апрель-май айларында 26 көмешкә кайнату очраклары ачыкланды. Бу яктан «иң актив, эшлекле» төбәк булып Якушкино (биш очрак), Каравыл Тавы һәм Абрыскино, Гәйтән авыллары тора. Аларның бу эштә танылган үз осталары бар. Әйтик, Каравыл Тавыннан И. Макаров, Абрыскинодан М. Миронова, Урта Камышлыдан Ю. Хвалеева, Гәйтәннән З. Имукова, Вишневая Поляңадан М. Морозова шундый танылганлыкка ия. Аларның бу «хезмәтләре» безнең тарафтан да «югары бәяләнде»: һәркайсына 100 сумнан 300 сумгача күләмдә штраф салынды.

x x x

Соңгы ике айда Октябрь район халык суды карары нигезендә 3 кеше (Норлаттан В. Сухов, И. Степко,

(Ахыры 4 нче биттә).

